2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авылы җирлеге Баграж-Никольский авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

22 ноябрь 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольский авыл җирлегенең Баграж-Никольский авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Баграж-Никольское авыл җирлегенең Баграж-Никольское авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Кечләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлауны, төзүне һәм ремонтлауны (су белән тәэмин итү торбаларын алмаштыру.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Баграж-Никольский авылы, Үзәк урам, 31б йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 кен эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Баграж-Никольский авыл җирлеге башлыгы Н.М. Новиков